РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.04.2017 № 348-п

2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм аларның норматив торышына китерү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль юл фондын төзү турында” Саба муниципаль районы Советының 2013 елның 09 октябрендәге 216 номерлы карары нигезендә финанслауны үзгәртү белән бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм аларның норматив хәленә китерү турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 27 декабрендәге 1303-п номерлы карары белән расланган 2015-2017 елларга (алга таба - Программа) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү турында» 2014 елның 27 декабрендәге 1303-п номерлы карары белән расланган үзгәрешләрне кертергә, кушымта нигезендә Программаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

– «2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм аларның норматив торышына китерү муниципаль программага үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 28 декабрендәге 1629-п номерлы карарының 1 пунктын;

– «2017-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм аларның норматив торышына китерү буенча муниципаль программаны раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 1328-п номерлы карары.

3. Саба муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә 2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм аларның норматив халәтенә китерүне тәэмин итәргә.

4. Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына муниципаль программаны тормышка ашыруга һәм 2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын юл фонды акчалары исәбеннән норматив хәлгә китерү өчен Саба муниципаль районы бюджетында акчалар кертүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.Б.Таиповка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
муниципаль район башкарма комитеты
җитәкчесенең социаль мәсьәләләр
буенча беренче урынбасары Т.Г.Шәрәфиев

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2017 елның 11
апрелендәге 348-п номерлы карарына
КУШЫМТА

Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең 2014
елның 27 ноябрендәге 1303-п
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

# 2015-2017 елларга ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ГОМУМИ ФАЙДАЛАНУДА БУЛГАН АВТОМОБИЛЬ ЮЛЛАРЫН ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ҺӘМ НОРМАТИВ ХӘЛГӘ КИТЕРҮ БУЕНЧА МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА

Б.Сабасы ш.т.б.

2014 ел

# ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Программа атамасы** | 2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм аларның норматив хәленә китерү буенча муниципаль программа (алга таба - Программа). |
| **Программаны төп эшләүчеләр** | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| **Программаның максаты һәм бурычлары** | Программаның максаты - халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын күтәрү, Саба муниципаль районы торак пунктларының урам-юл инфраструктурасы эшчәнлеген җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын норматив хәлгә китерү юлы белән тәэмин итү.<br>Әлеге максатны гамәлгә ашыру өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:<br>- Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү планын эшләргә |
| **Программаны гамәлгә ашыру срогы** | 2015-2017 еллар |
| **Программаны финанслау күләмнәре** | 2015-2017 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме Саба муниципаль районы бюджеты хисабына **35 667 667,78** сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2015 ел - **9 200 000** сум;<br>2016 ел - **8 972 000** сум;<br>2014-2015 елларның калган өлеше - юл хәрәкәте куркынычсызлыгы чараларына - **1.517 267,78** сум;<br>2017 ел - **10 300 000** сум.<br>2015-2016 елның калган өлеше юл хәрәкәте куркынычсызлыгы чараларына - **5 678 400,00** сум;<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында һәм тиешле елга һәм план чорына Саба муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда **ел саен** төгәлләштерелергә тиеш. |
| **Программаны башкаручылар** | Саба муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетлары, Саба муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге, Саба муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары. |
| **Программаның үтәлешен тикшереп торуны оештыру системасы** | Программаны гамәлгә ашыруны Саба муниципаль районы Советы тикшереп тора. |
| **Программаны гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәләре** | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы торак пунктларының урам-юл инфраструктурасының тулы канлы эшчәнлеге нигезендә район халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү.<br>Программаның нәтиҗәлелеге Программаның бүлекчәләрендә билгеләнгән максатчан күрсәткечләргә ирешү дәрәҗәсе буенча бәяләнә. |

## 1. Саба муниципаль районы торак пунктларының урам-юл инфраструктурасына характеристика.

2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программа (алга таба - Программа) Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль юл фондын төзү турында» 2013елның 09 октябрендәге 216 номерлы карары нигезендә эшләнгән.

Саба муниципаль районы 1930 елда төзелгән, Татарстанның төньягында Кама алды икътисадый зонасының үзәк өлешендә урнашкан. Районның мәйданы 1098 кв.км., Татарстан Республикасының гомуми мәйданының 1,62%ын тәшкил итә. унтугыз авыл һәм бер шәһәр җирлеген 67 торак пункт берләштерә, халыкның саны 01.01.2014 ел мәгълүматлары буенча 31047 кеше тәшкил иткән.

Район территориясе Мишә елгасы бассейнының өске өлешен алып тора. Нигездә, бу - елга үзәннәре белән киң һәм сөзәк түтәлләргә бүленгән калкулыклы тигезлек. Алар, үз чиратында, кечерәк елгаларның озын чокырлары һәм вак үзәннәре белән вак икенчел калкулыкларга һәм сөзәк калкулыкларга бүлгәләнә.

Район үзәге - Б.Саба бистәсе, республикабыз башкаласы - Казан шәһәреннән 98 чакрым ераклыкта, Шәмәрдән тимер юл станциясеннән 22 чакрым ераклыкта, Нократ Аланыннан 60 чакрым ераклыкта урнашкан.

Саба районы, Татар АССР составында административ-территориаль берәмлек буларак, 1930 елның 10 августында ВЦИК карары белән төзелгән.

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлеге 2005 елның 31 гыйнварындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән.

Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының озынлыгы 01.01.2014 ел торышы буенча

1 нче таблица

| | 01.01.2014 ел торышы буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юллары | Барлыгы (км) | Озынлыгы (км), шул исәптән | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ц/б | а/б | вак таш, гравий | грунт |
| 1 | Автоюллар җирлекләрнең һәм шәһәрләрнең урам-юл челтәрен исәпкә алмыйча | 48,13 | | 8,77 | 1,16 | 38,2 |
| 2 | Җирлекләрнең урам-юл челтәре | 210,4 | 1,72 | 39,01 | 31,73 | 137,94 |
| 3 | Шәһәрнең урам-юл челтәре | 58,73 | 0 | 51,55 | 1,22 | 5,96 |
| 4 | Барлыгы: | 317,26 | 1,72 | 99,33 | 34,11 | 182,1 |
| 5 | Норматив таләпләргә җавап бирми торган җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының озынлыгы | 181,8 км. - бу гомуми озынлыктагы 57,3 % тәшкил итә. | | | | |

Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланучы булган автомобиль юлларына хезмәт күрсәтүче оешмалар: «Саба ТКХ МПП» ААҖ, «Саба районының Шәмәрдән ТКХ МПП» ААҖ, «Рамазан» ҖЧҖ.

Автотранспорт предприятиеләре: «Яшен» ҖЧҖ.

Мәгариф учреждениеләре укучыларын йөртүче автотранспорт предприятиесе: «Яшен» ЖЧЖ. Мәктәп маршрутлары - 37, Мәктәп автобуслары - 22 берәмлек. Гомуми белем бирү мәктәпләре саны - 23, шул исәптән урта - 20, төп - 3 берәмлек.

2012-2014 елларда Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү.

2 нче таблица

<table>
<tr><td rowspan="2">Өслек тибы</td><td colspan="2">2012</td><td colspan="2">2013</td><td colspan="2">2014</td></tr>
<tr><td>асфальт</td><td>вак таш</td><td>асфальт</td><td>вак таш</td><td>асфальт</td><td>вак таш</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү (км)</td><td>15,05</td><td>4,58</td><td>(12156,8 кв. м.)</td><td>3,48</td><td>6,5</td><td>7,11</td></tr>
<tr><td colspan="2">19,66</td><td colspan="2">3,48</td><td colspan="2">13,61</td></tr>
</table>

## 2. Саба муниципаль районының юл инфраструктурасы сыйфатын үстерүнең институциональ проблемалары.

Икътисадый киңлекнең состав өлеше булган юл тармагы икътисадны үстерүгә, шәһәр җирлегенең, авыл җирлекләренең һәм аерым торак пунктларның социаль өлкәсен яхшыртуга актив йогынты ясый һәм транспорт-коммуникация системасын үстерүдә мөһим роль уйный. Районның бөтен икътисады кебек үк, юл тармагы да даими үсә. Әмма юл челтәрен үстерү темплары бүгенге заман таләпләренә җавап бирми. Автомобильләшү һәм юл челтәрен үстерү арасындагы аерма бүген кискен характерга ия булды.

Саба муниципаль районы юл инфраструктурасының сыйфатын үстерү проблемалары булып түбәндәгеләр тора:

1. Үз-үзен тәэмин итүнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы (икътисадый, финанс, социаль).

2. Юл хуҗалыгы объектларының техник паспортлары һәм аларны әзерләүгә финанс чаралары булмау.

3. Җирле бюджетлар керемнәренең түбән дәрәҗәсе һәм юл эшчәнлеген җитәрлек финансламау.

Әлеге Программа югарыда әйтелгән институциональ проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән.

## 3. Саба муниципаль районының юл инфраструктурасының сыйфатын күтәрү өлкәсендәге проблемаларны хәл итү буенча төп бурычлар.

- Автомобиль юлларының гамәлдәге юл челтәрен һәм аларда ясалма корылмаларны саклау һәм торгызу.
- Автомобиль юлларыннан файдаланучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле дәрәҗәдә аларның транспорт-эксплуатация күрсәткечләрен тәэмин итү.
- Төзекләндерү һәм яхшы хәлдә тоту буенча эшләрне вакытында һәм сыйфатлы башкару.

## 4. 2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм

**аларның норматив торышына китерү буенча муниципаль программаның төп чаралары.**

3 нче таблица

<table>
<tr><th>№ т/б</th><th>Чараның атамасы</th><th>Башкаручылар (килешү буенча)</th><th>Финанслау күләме һәм чыганаклары (мең сум).</th><th>Үтәү вакыты</th></tr>
<tr><td>1</td><td>Смета документларын эшләү</td><td>Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирлекләр башлыклары</td><td rowspan="5">Саба муниципаль районы бюджеты, 35 667,78 сум, шул исәптән:<br>2015 ел- 9 200 000 сум;<br>2016 ел - 8 972 000 сум;<br>2014-2015 елның калган өлешен БДД буенча чараларга - 1 517 267,78 сум;<br>2017 ел - 10 300 000 сум.<br>2015-2016 елның калган өлешен БДД буенча чараларга - 5 678 400,00 сум;<br>әлеге Программаның 4 таблицасында күрсәтелгән финанс чараларын бүлү нигезендә</td><td>Агымдагы елның апрель - март айлары</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Смета документларын тикшерү</td><td>"Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчысы хезмәте» МУП, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Саба районы территориаль бүлеге</td><td>тикшерүгә бирелгән көннән башлап 1 атна дәвамында</td></tr>
<tr><td>3</td><td>Төзекләндерү эшләрен башкару</td><td>Ачык аукцион нәтиҗәләре буенча электрон сатуларда откан подрядчы оешма</td><td>контрактта күрсәтелгән сроклар</td></tr>
<tr><td>4</td><td>Башкарыла торган эшләрнең сыйфатын техник күзәтү һәм тикшереп тору</td><td>«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчысы хезмәте» МУП</td><td>эшләр эшләнү дәвамында</td></tr>
<tr><td>5</td><td>Башкарылган эшләрне кабул итү һәм объектны файдалануга тапшыру</td><td>Заказ бирүче - (объектның баланс тотучысы),<br>Заказ бирүче-төзүче - "ТР Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчысы хезмәте" МУП</td><td>төзекләндерү эшләрен төгәлләү буенча</td></tr>
</table>

## 5. 2015-2017 елларда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юл фондының финанс чараларын бүлү.

4 нче таблица

| № | Җирлекләр исеме | Еллар буенча бүленеш (сум) | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2015 | 2016 | 2017 |
| 1. | Саба шәһәр җирлеге | 1 385 809,31 | | 7 090 783,00 |
| 2. | Арташ авыл җирлеге | | | |
| 3. | Олы Кибәче авыл җирлеге | | | 1 073 112,18 |
| 4. | Олы Нырты авыл җирлеге | 548 680,47 | | |
| 5. | Олы Шыңар авыл җирлеге | | | |
| 6. | Курсабаш авыл җирлеге | 668 703,22 | | 894 489,40 |
| 7. | Югары Симет авыл җирлеге | | | |
| 8. | Явлаштау авыл җирлеге | 511 739,59 | | |
| 9. | Эзмә авыл җирлеге | 784 732,62 | | |
| 10. | Иштуган авыл җирлеге | | | |
| 11. | Килдебәк авыл җирлеге | 560 599,05 | | |
| 12. | Түбән Шытсу авыл җирлеге | 898 519,87 | | |
| 13. | Мишә авыл җирлеге | 2 330 000,0 | | |
| 14. | Мичән авыл җирлеге | | 2 861 763,73 | |
| 15. | Сатыш авыл җирлеге | 701 892,12 | 2 124 193,17 | 1 241 615,42 |
| 16. | Иске Икшермә авыл җирлеге | | | |
| 17. | Тимершык авыл җирлеге | 809 323,74 | 1 993 021,55 | |
| 18. | Шекше авыл җирлеге | | | |
| 19. | Юлбат авыл җирлеге | | 1 993 021,55 | |
| 20. | Шәмәрдән авыл җирлеге | | | |
| | Барлыгы БДД чаралары буенча (01.01.2017 торышына калдыклар исәбеннән) | | 1 517 267,78 | 5 678 400,00 |
| | **БАРЛЫГЫ:** | **9 200 000,00** | **10 489 267,78** | **15 978 400,00** |